МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.02.2020 г.Казань № 71

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 11 мартында 6550 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666, 14.11.2019 №1012 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 6 февралендәге 71 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.5 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшенә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дару чаралары һәм даруханә ассортиментындагы башка товарлар сатып алу өчен түләү тәртибе турында нигезләмә (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru, 2019, 3 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшенә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дару чаралары һәм даруханә ассортиментындагы башка товарлар сатып алу өчен түләү кысаларында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре)» дәүләт казна учреждениесе һәм кредит оешмалары арасында үзара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru, 2019, 3 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки

муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

гаилә әгъзалары – Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә гаилә составында исәпкә алына торган затлар.

блокланган максатчан шәхси счет – банк яки башка кредит оешмасында ачылган, дару чаралары сатып алу өчен түләү алу максатларында Үзәк белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән затның шәхси счеты.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында үтенеп язылган гариза аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 п.).»;

2 бүлектә:

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Банкта яки башка кредит оешмасында законнарда билгеләнгән тәртиптә социаль түләүләрне күчерү өчен ачылган шәхси счет реквизитларын (балага пособиене банк яки башка кредит оешмасы аша алган очракта) күрсәтеп, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә балага айлык пособие билгеләү турында гариза.»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 16 яшьтән олырак баланың (балаларның) Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан дәүләт яки муниципаль гомуми белем бирү оешмасында яки шәхси гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмә.»;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

гаилә әгъзаларында күчемсез мөлкәт булуы турында белешмәләр (Росреестрдан);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

бала(лар)ның тууы Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта – балаларның туунын дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

уналты яшьтән олырак баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирү оешмасыннан);

опека (химаячелек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, опекунның (химаяченең) баланы асраган өчен ала торган акча күләме һәм тәрбиягә алган ата-аналарга тиешле бүләкләү суммалары турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) зат тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

социаль түләү күләме турында мәгълүматлар:

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Эчке эшләр министрлыгыннан);

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Оборона министрлыгыннан);

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләр, компенсация түләүләре һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган матди тәэминатлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эшсезлек буенча пособиеләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән);

эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән);

һөнәри белем алган һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган чорда гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән);

җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән);

вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән);

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарыннан);

эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан);

йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан);

йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие (социаль яклау органнарыннан яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан);

яшь ярымлык яшенә җиткәнче бала карау буенча ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарыннан яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан);

I төркем инвалидны, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кешеләр тәрбиясенә мохтаҗ яки 80 яшенә җиткән өлкән кешене карый торган, эшкә сәләтле эшләми торган затларга айлык компенсация түләүве (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны карый торган эшкә сәләтле эшләми торган затларга айлык түләү (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтә торган хәрби хезмәткәрнең баласына ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарыннан);

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен компенсация (социаль яклау органнарыннан);

читләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими рәвештә мохтаҗ 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү (социаль яклау органнарыннан);

берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә яшь ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарыннан);

гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия (шул исәптән субсидия-ташламалар) (социаль яклау органнарыннан);

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсация (социаль яклау органнарыннан);

беренче бала туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә ай саен түләнә торган түләү (социаль яклау органнарыннан).

Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен

күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны»;

«Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәнең 3.6, 3.7, 3.11, 3.12 пунктлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган Тәртип»;

2.8 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әгәр балага пособие сорап мөрәҗәгать иткән ата-анада балага карата алимент йөкләмәләре барлыкка килсә»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

үзара хезмәттәшлек турында Үзәк белән килешү төзегән банктан яки башка кредит оешмасыннан блокланган махсус шәхси счет реквизитлары турында (гариза бирүче булып өч яшенә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) мөрәҗәгать иткән очракта);

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, вәкаләтле органнардан;

халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән – эшсезлек буенча пособие күләме турында;

эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

һөнәри белем алган һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган чорда гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында түләнә торган түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләнә торган түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә айлык матди тәэминатлар һәм күләмнәре турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

социаль яклау органнарыннан йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

балага яшь ярым булганчы социаль яклау органнарыннан түләнә торган бала карауга бәйле айлык пособие күләме турында, социаль яклау органнарыннан;

чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтә торган хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен компенсация күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

читләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими рәвештә мохтаҗ 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә яшь ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидия (шул исәптән субсидия-ташламалар) күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсация күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарыннан;

беренче бала туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә, социаль яклау органнарыннан – айлык түләү күләме турында;

18 яше тулмаган инвалид-баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә читләр тәрбиясенә мохтаҗ яки 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге кешене карый торган, эшкә сәләтле эшләми торган затларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган айлык компенсация түләүләренең күләме турында, – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

вәкаләтле оешмалардан – гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган белешмәләр.»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге

белгечә электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, – вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында – җирле үзидарә органнарына;

опека (химаячелек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, опекунның (химаяченең) баланы асраган өчен ала торган акча күләме һәм тәрбиягә алган ата-налларга тиешле бүләкләү суммалары турында (җирле үзидарә органнарына);

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләме турында, – социаль яклау органнарына яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарына;

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләме турында, – социаль яклау органнарына яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарына;

яшь ярымлык яшенә җиткәнче баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында, – социаль яклау органнарына яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) зат тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында, – вәкаләтле органга;

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында, – Россия Эчке эшләр министрлыгына;

эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре күләме турында, – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарына;

беренче бала туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә, социаль яклау органнарына – айлык түләү күләме турында;

18 яше тулмаган инвалид-баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә читләр тәрбиясенә мохтаҗ яки 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге кешене карый торган, эшкә сәләтле эшләми

торган затларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган айлык компенсация түләүләренең күләме турында, – Россия Федерациясе Пенсия фондына;

гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында, – вәкаләтле органга;

уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында, – гомумбелем бирү оешмаларына;

гаилә әгъзаларында күчемсез мөлкәт булуы турында – Росреестрга;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында – җирле үзидарә органнарына;

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында – вәкаләтле органнарга;

гариза тапшыручының паспорты чын булуын раслау турында, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса – Татарстан Республкиасы буенча Эчке эшләр министрлыгына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.5.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк бүлеге белгече алынган, 3.4.1 пунктта күрсәтелгән белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә, шулай ук гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтеннән файдаланучының вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештә карар проекты рәсмиләштерә;

балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган гариза бирүче тарафыннан ачылган блокланган максатчан шәхси счет реквизитлары турындагы белешмәләр Үзәк бүлегендә булган очракта, өч яшькә кадәрге балага пособие билгеләү турындагы карар проектында өстәмә рәвештә дару чаралары сатып алу өчен түләү билгеләү турында мәгълүмат күрсәтелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештәге карар проекты.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә гаризада аның тарафтан күрсәтелгән ысул (алга таба – гаризада күрсәтелгән хәбәр итү ысулы) белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) хәбәр итә. Бу вакытта, өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган гариза бирүче тарафыннан ачылган блокланган максатчан шәхси счет реквизитлары турындагы белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаган очракта, балага пособие билгеләү турындагы хәбәр язуында Үзәк бүлеге белгече шулай ук гариза бирүчегә блокланган максатчан шәхси счет ачу кирәклеге турында да күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Үзәк бүлеге белгеченә балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла;

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында, даруларга түләү билгеләү турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны җибәрү.»;

1 нче кушымтада «Киңәш итеexcept торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

РӘВЕШЕ

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ___ номерлы бүлегенә
___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага айлык пособие билгеләү (бирү) турында
карар

№ ________ _________ 20__ ел.

___________________________________________________
Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Гариза бирүченең адресы: ____________________________________________
___________________________________________________

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

нигезендә 16 яшькә кадәрге (гомуми белем бирү оешмасында укучы бала өчен – ул укып бетергәнче, ләкин 18 яше тулганчы гына) айлык пособие билгеләргә (бирергә)

_______________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________ сум күләмендә

Түләү срогы: ___башлап____кадәр

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары нигезендә дару чаралары сатып алу өчен 5 000 сум күләмендә түләү билгеләргә

Түләү ысулы: __________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге җитәкчесе

___________________________

________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) __________________ ________________

(Ф.И.А.) (имза)

мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге белгече

________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) __________________ ________________

(Ф.И.А.) (имза)

Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):

язмача

смс-хәбәр белән _______________________

(телефон номеры)

_____________________________ электрон почтасы аша

(электрон почта адресы)

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша

* «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ бүлегендә өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган гариза бирүче тарафыннан ачылган блокланган максатчан шәхси счет реквизитлары турында белешмәләр булган очракта, балага айлык пособие билгеләү (бирү) турындагы карарда күрсәтелә

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы бүлегенә
____________________________________________
____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага айлык пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында
карар

№ ________ _________ 20__ ел.

______________________________________________________________
Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Гариза бирүченең адресы: ____________________________________________
«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 16 яшькә кадәрге (гомуми белем бирү оешмасында укучы бала өчен – ул укып бетергәнче, ләкин 18 яше тулганчы гына) айлык пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга
______________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлеге җитәкчесе
____________________________
_________________________________
муниципаль районы һәм шәһәр округында) __________________________ __________
(Ф.И.А.) (имза)

мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече
_________________________________
муниципаль районы һәм шәһәр округында) __________________________ __________
(Ф.И.А.) (имза)
Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
язмача
смс-хәбәр белән ________________________
(телефон номеры)
______________________________ электрон почтасы аша
(электрон почта адресы)
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша».